КОМИССИЯ ПРИ ПРЕЗИДЕНТЕ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО ВОПРОСАМ СОХРАНЕНИЯ
И РАЗВИТИЯ ТАТАРСКОГО ЯЗЫКА

420060, г. Казань, площадь Свободы, 1

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ КАРШЫНДАГЫ
ТАТАР ТЕЛЕН САКЛАУ ҺӘМ ҮСТЕРҮ
МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ КОМИССИЯСЕ

420060, Казан шәһәре, Ирек мәйданы, 1

Тел.: (843) 267-63-31. E-mail: gossov@gossov.tatarstan.ru.

09.10.2020 16-4-5595

Татарстан Республикасы
муниципаль районнары
башлыкларына

«TATAR сүзе» республикакүләм конкурсы турында

Хөрмәтле җитәкчеләр!

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү мәсьләләре комиссиясенең чираттагы утырышында татар әдәби әсәрләрен сәнгатьле укучыларның «TATAR СҮЗЕ» республикакүләм конкурсы игълан ителде. Бәйге татар телен һәм әдәбиятын пропагандалау, татар халкының классик шигърият дигән тирән, бай тарихи-мәдәни хәзинәсен саклап калу, милли мәдәният өлкәсендә китапның урынын һәм әһәмиятен билгеләү, нәфис сүз юнәлешендә талантлы башкаручыларны барлау, аларга ярдәм итү һәм иҗади мөмкинлекләрен үстерү юнәлешендә зур әһәмияткә ия.

Бу уңайдан Сез җитәкләгән районда яшәүче нәфис сүз осталарына әлеге проект турында мәгълүмат җиткерүегезне һәм конкурста актив катнашуларын оештыруыгызны сорыйм.

Белешмәләр өчен телефоннар: 8(919) 690-04-22, 8(843) 277-19-91 (Гөлчәчәк Рамил кызы Зөлкәева).

Кушымта: 7 биттә.

Ихтирам белән,
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе урынбасары,
Комиссия рәисе М.Г. Әхмәтов

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН
ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП

Сертификат: 3BAFAD00E3AADABA40BE1752F465D932
Владелец: Ахметов Марат Готович
Действителен с 11.10.2019 до 11.01.2021



ЭЛЕКТРОННЫЙ ПАРЛАМЕНТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**Татар әдәби әсәрләрен сәнгатьле укучыларның «TATAR СҮЗЕ» республикакүләм конкурсы турында нигезләмә**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә татар әдәби әсәрләрен сәнгатьле укучыларның «TATAR СҮЗЕ» республикакүләм конкурсын (алга таба – Конкурс) әзерләү һәм үткәрү тәртибен билгели.

1.2. Конкурсны гамәлгә куючы – Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясе (алга таба – Комиссия).

1.3. Конкурсны оештыручы – «Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе (алга таба – Оештыручы).

## 2. Конкурсның максатлары һәм бурычлары

2.1. Конкурс татар телен һәм әдәбиятын популярлаштыру, татар нәфис сүзенә кызыксыну уяту, шигъри аһәңне тоярга өйрәтү максатларында уздырыла.

2.2. Конкурсның бурычлары түбәндәгеләр:

– татар телен һәм мәдәниятен саклап калу, аларның үсешенә ярдәм итү;

– татар халкының бай тарихи-мәдәни казанышы буларак, татар классик әдәбиятын саклап калу;

– татар әдәбиятына кызыксыну уяту;

– башкаручыларның иҗади мөмкинлекләрен үстерү, талантлы нәфис сүз осталарына ярдәм итү;

– башкару осталыгын камилләштерү өчен шартлар тудыру, талантлы башкаручыларның профессиональ сәхнәгә чыгуына ярдәм итү.

## 3. Жюри

3.1. Комиссия тарафыннан 7 (җиде) кешедән торган жюри төзелә, ул мәдәният һәм сәнгать өлкәсендәге белгечләрдән, җәмәгатьчелек вәкилләреннән тора. Жюри составына рәис, рәис урынбасары, җаваплы секретарь һәм жюри әгъзалары керә.

3.2. Жюри утырышында кимендә 5 (биш) әгъза катнашса, ул тулы хокуклы дип санала.


ЭЛЕКТРОННЫЙ ПАРЛАМЕНТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

3.3. Жюри карарлары коллегиаль кабул ителә. Тавышлар (баллар) саны тигез булганда, жюри рәисенең тавышы хәлиткеч була.

## 4. Конкурста катнашучылар

4.1. Конкурста катнашуга яшь ягыннан чикләүләр юк.

4.2. Конкурста катнашучылар түбәндәге категорияләргә бүленә:

а) 10 яшькә кадәрге (10 яшьне дә кертеп) катнашучылар;

б) 11 яшьтән 17 яшькә кадәрге (17 яшьне дә кертеп) катнашучылар;

в) 18 яшьлек һәм өлкәнрәк катнашучылар;

г) профессиональ катнашучылар – театр, кино, концерт оешмалары профессиональ артистлары, театр белеме бирү педагоглары, дикторлар.

4.3. Әлеге Нигезләмәнең 8.3 пункты нигезендә конкурс эшен тапшыру мизгеленә катнашучының яшенә бәйле рәвештә жюри катнашучыларны әлеге Нигезләмәнең 4.3 пунктындагы «а» – «в» пунктчаларында күрсәтелгән категорияләргә бүлә.

4.4. Конкурста катнашучылар әлеге Нигезләмәнең 4.3 пунктындагы «г» пунктчасында күрсәтелгән категориягә жюри тарафыннан, Конкурста катнашучының профессиональ эшчәнлеге турындагы белешмәләргә таянып, Конкурс үткәрү барышында кертелергә мөмкин.

## 5. Конкурсның номинацияләре

5.1. Конкурс түбәндәге номинацияләрдә үткәрелә:

а) поэзия (шигырь, поэмалардан өзекләр);

б) проза;

в) мәсәл.

5.2. Һәрбер номинациядә һәр категория өчен 3 (өч) премия карала (әлеге Нигезләмәнең 4.3 пунктындагы «а» – «в» пунктчалары):

10 яшькә кадәрге (10 яшьне дә кертеп) катнашучылар арасында:

I урын – 30 000 (утыз мең) сум

II урын – 25 000 (егерме биш мең) сум

III урын – 20 000 (егерме мең) сум.

11 яшьтән 17 яшькә кадәрге (17 яшьне дә кертеп) катнашучылар арасында:

I урын – 45 000 (кырык биш мең) сум

II урын – 35 000 (утыз биш мең) сум

III урын – 25 000 (егерме биш мең) сум.



ЭЛЕКТРОННЫЙ ПАРЛАМЕНТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

18 яшьлек һәм өлкәнрәк катнашучылар арасында:
I урын – 50 000 (илле мең) сум
II урын – 40 000 (кырык мең) сум
III урын – 30 000 (утыз мең) сум.

5.3. Профессиональ катнашучылар (әлеге Нигезләмәнең 4.3 пунктындагы «г» пунктчасы) өчен, номинацияләргә бүлмичә, барлыгы 3 (өч) премия карала:
I урын – 100 000 (йөз мең) сум
II урын – 80 000 (сиксән мең) сум
III урын – 70 000 (җитмеш мең) сум.

## 6. Конкурс эшләренә таләпләр

6.1. Конкурс татар телендә үткәрелә.
6.2. Конкурста катнашучылар барлык номинацияләр (поэзия, проза, мәсәл) буенча конкурс эшләре тәкъдим итәргә мөмкин.
6.3. Конкурс эше яттан сөйләнгән яисә укылган монолог яки диалог рәвешендә әдәби әсәрне бәян итүдән гыйбарәт чыгыш булырга тиеш.
6.4. Катнашучының чыгышы музыкаль бизәлеш белән барырга мөмкин.
6.5. Бәян ителә торган әдәби әсәр катнашучының яшенә туры килергә тиеш.
6.6. Чыгыш ясау вакыты 5 (биш) минуттан артмаска тиеш.

## 7. Конкурсны оештыручы

Оештыручы:
– тапшырылган эшләрнең Конкурс таләпләренә туры килүен, Конкурста катнашучыларның Конкурс таләпләрен үтәвен тикшереп тора;
– конкурс документациясен алып бара;
– законнар үтәлешен, шул исәптән Конкурста катнашучылар бәян итә торган әсәрләргә – интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәсенә хокуклар турындагы законнар, персональ белешмәләр турындагы законнар, граждан сурәтен саклау турындагы законнар таләпләре үтәлешен тикшереп тора;
– жюри эшен тәэмин итә;


ЭЛЕКТРОННЫЙ ПАРЛАМЕНТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

– Комиссиягә һәм массакүләм мәгълүмат чараларына Конкурс үткәрү барышы турында оператив мәгълүмат бирә;

– Конкурсның гала-концертын үткәрүне оештыра.

## 8. Конкурсны үткәрү һәм аңа йомгак ясау тәртибе

8.1. Конкурс ике этапта уздырыла һәм гала-концерт белән төгәлләнә.

8.2. Конкурс эшләрен сайлап алу шарты катнашучыларның башкару осталыгыннан (актерлык осталыгы, дикция һ.б.), шулай ук чыгышның (шул исәптән костюмның, реквизитның, музыкаль бизәлешнең) оригиналь булуыннан гыйбарәт.

8.3. Беренче этап (сайлап алу этабы) барышында Конкурста катнашучылар конкурс эшләрен видеоязма рәвешендә электрон форматта **tatarsuze@tatfil.ru** электрон почта адресына яисә WhatsApp мессенджеры аша **+7 (919) 690-04-22** номерына җибәрәләр. Конкурс эшенә Конкурста катнашучының визит карточкасы (контакт белешмәләре) кушып бирелергә тиеш.

8.4. Конкурс эшләре беренче этапта 2020 елның 15 декабренә кадәр (15 декабрьне дә кертеп) кабул ителә.

8.5. Жюри тапшырылган конкурс эшләрен Конкурс номинацияләре һәм катнашучылар категорияләре буенча бүлә.

8.6. Жюри тапшырылган конкурс эшләрен карый һәм катнашучыларны Конкурсның икенче этабына уздыру турында ачык тавыш бирү юлы белән карар кабул итә.

8.7. Икенче этапта Конкурста катнашучылар жюри алдында чыгыш ясый.

8.8. Конкурсның икенче этабы 2021 елның 20 февралендә уздырыла. Чыгышларның урыны һәм төгәл графигы жюри тарафыннан билгеләнә, Оештыручының рәсми сайтында, социаль челтәрләрдә урнаштырыла һәм массакүләм мәгълүмат чараларында басыла.

8.9. Жюри Конкурсның икенче этабында тәкъдим ителгән конкурс эшләрен карый һәм тиешле категорияләр һәм номинацияләр буенча Конкурста җиңүчеләр турында ачык тавыш бирү юлы белән карар кабул итә. Жюри карары беркетмә белән рәсмиләштерелә. Моннан тыш, Конкурсның икенче этабында жюри гала-концертта күрсәтеләчәк конкурс эшләрен билгели.

8.10. Жюри бернинди дә призлы урыннар бирмәскә йә аерым номинацияләр һәм катнашучылар категорияләре буенча гына призлы урыннар бирергә хокуклы.

8.11. Оештыручы Конкурсның йомгаклары турында Комиссиягә хәбәр итә.

8.12. Конкурста җиңүчеләр турында мәгълүмат Оештыручының рәсми сайтында, социаль челтәрләрдә урнаштырыла һәм массакүләм мәгълүмат чараларында басыла.

8.13. Конкурсның гала-концерты Халыкара туган тел көнендә – 2021 елның 21 февралендә үткәрелә.

8.14. Конкурста җиңүчеләр гала-концертта бүләкләнә.

## 9. Йомгаклау нигезләмәләре

9.1. Конкурста җиңүчеләргә акчалата премияләр Конкурска бирелгән акчалар исәбеннән түләнә.

9.2. Оешмалар һәм предприятиеләр Конкурста катнашучыларга махсус бүләкләр һәм премияләр бирергә мөмкин.

9.3. Әлеге Нигезләмәдә күрсәтелмәгән мәсьәләләр, Комиссиянең рәисе белән килештерелеп, Оештыручы тарафыннан хәл ителә.



ЭЛЕКТРОННЫЙ ПАРЛАМЕНТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**Татар әдәби әсәрләрен сәнгатьле укучыларның**
**«TATAR СҮЗЕ» республикакүләм конкурсының**
**ЖЮРИ СОСТАВЫ**

| | | |
|---|---|---|
| 1. | Фәйзрахманов<br>Айдар Фәтхрахман улы | жюри рәисе, Россия Федерациясенең Атказанган артисты, Татарстан Республикасының Халык артисты, Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенең сәнгать җитәкчесе, Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты *(килешү буенча)* |
| 2. | Гыйләҗев<br>Искәндәр Аяз улы | жюри рәисе урынбасары, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты директоры, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзасы, Татарстан Республикасының Атказанган фән эшлеклесе, Татарстан Республикасының Фән һәм техника өлкәсендә дәүләт премиясе лауреаты *(килешү буенча)* |
| 3. | Мөхәммәтшин<br>Рүзәл Фәиз улы | жюриның җаваплы секретаре, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Мәдәният һәм Татарстан Республикасы халыклары телләрен үстерү идарәсенең Татарстан Республикасы халыклары телләрен үстерү секторы мөдире, шагыйрь, драматург, М.Җәлил исемендәге республика премиясе лауреаты *(килешү буенча)* |
| 4. | Салихов<br>Данил Хәбибрахман улы | Татарстан Республикасы Язучылар берлеге рәисе, драматург, прозаик, Татарстан Республикасының Атказанган сәнгать эшлеклесе *(килешү буенча)* |
| 5. | Әхмәтҗанов<br>Илдус Хәниф улы | Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры актеры, Россия Федерациясенең Атказанган артисты, Татарстан Республикасының Халык артисты, |

Документ создан в электронной форме. № 16-4-5595 от 09.10.2020. Исполнитель: Насыйхова Л.Р.
Страница 7 из 9. Страница создана: 08.10.2020 12:30

| | | |
|---|---|---|
| | | М.Җәлил исемендәге республика премиясе лауреаты, Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты *(килешү буенча)* |
| 6. | Гарипова<br>Илсөяр Вазыйх кызы | шагыйрә, Татарстан Республикасының Атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстан Республикасы Язучылар берлеге әгъзасы *(килешү буенча)* |
| 7. | Кыямов<br>Илдар Әгъләметдин улы | «Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе алып баручысы, «Манзара» тапшыруының баш мөхәррире<br>*(килешү буенча)* |
| 8. | Галимуллин<br>Фоат Галимулла улы | татар әдәбияты белгече, КФУ профессоры, филология фәннәре докторы, Татарстанның һәм РФның атказанган мәдәният хезмәткәре *(килешү буенча)* |
| 9. | Сәләхова<br>Резедә Нурислам кызы | К.Тинчурин исемендәге татар дәүләт драма һәм комедия театры актрисасы, М.Җәлил исемендәге республика премиясе лауреаты *(килешү буенча)* |



ЭЛЕКТРОННЫЙ ПАРЛАМЕНТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Лист согласования к документу № 16-4-5595 от 09.10.2020
Инициатор согласования: Насыйхова Л.Р.
Согласование инициировано: 08.10.2020 12:27

**Лист согласования** Тип согласования: **последовательное**

| N° | ФИО | Срок согласования | Результат согласования | Замечания |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Зарипов А.Р. | | Согласовано 08.10.2020 - 16:36 | - |
| 2 | Ахметов М.Г. | | Подписано 09.10.2020 - 12:09 | - |


ЭЛЕКТРОННЫЙ ПАРЛАМЕНТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН